**Игелекле остаз**

*Зәңгәр күзең, күз керфегең*

*Тибрәндереп карама.*

*Күз карашың ук шикелле*

*Йөрәгемә кадама.*

*Әй, бөдрә чәч, зәңгәр күз,*

*Әйтмәм, бәгырем, авыр сүз.*

Сәләй Вагыйзов Башкортстанның Стәрлетамак шәһәрендә туып үскән, затлылыгы, зыялылыгы йөзенә, чыккан, зәңгәр күзле, сөйкемле Рәмзиясенә багышлап әлеге "Зәңгәр күз" җырын (халык сүзләре, Әнвәр Бакиров көе) җырлый торган булган.

Еллар үткән саен бу күзләрнең төсе һич кенә дә тоныкланмаган, ә киресенчә, яктыра, ялкынлана барган. Тора-бара, бөдрә чәчләргә көмеш кунып, йөзләргә ягымлы гына сырлар төшә. Ә күңеле Һаман да шул Сәләй беренче күргән көндәге кебек: ачык, гади һәм якты. Укучыларының күңелендә дә ул әнә шулай сакланган. М.Мәһдиевнең иң беренче әсәрендәге Рәмзияне (автор аны Рәбига дип атый) генә алыйк:

"*Буран, буранның, буранга...Шул арада бу сүзләр барысы да вак кисәкләр булып оча башлыйлар...*

*Рәбига апаның дәресе дүшәмбедә беренче сәгать булганлыктан соңга калучылар да, йоклап утыручылар да була. Йоклаган укучыларга ул ачуланмый. Тик дәресеңне генә белеп кил.*

- *Сезнең каныгыз азайган,* - *ди ул. – менә сугыш бетәр, теләгәнчә шикәр, яшелчә, җиләк-җимеш ашарсыз. – Йоклау кан азлыктан ул...*"

Гадәттә, без йоклап утырган укучыларны ачуланырга күнеккән, ә ул киресенчә, мондый балаларның да күңеленә юл тапкан. Ипигә дә туймаган, чабаталы авыл малайлары күңелендә җиңүгә ышаныч, өмет уяткан.

Икече укучысы Г.Ахунов өчен Рәмзия Вәлитова чишмәгә тиң:

*"Рәмзия апаның, тау-ташлар актарып чыккан саф сулы чишмә шикелле, яктыга омтылуы, илебез биргән белемне үзендә калдырмыйча, меңләгән*

*балага күчерүе – бу үзе үк инде саф суы белән кешеләрнең сусынын баскан Чишмә образын хәтерләтә. Мин аның нинди әйбәт укытучы булганлыгын ак кәгазь бите янына утырган саен искә төшерәм. Ул бездә туган телебезгә, Тукай мирас итеп калдырган телгә мәхәббәт уятты. Телнең грамматикасына, синтаксисына өйрәтергә мөмкин, дөрес итеп нокталы өтер куярга өйрәтергә мөмкин, әмма туган телгә карата мәхәббәт тәрбияли алмасаң, өйрәтеп йөргәннәрем бушка китте дип исә. Теле булмаган язучыны, телгә битараф калган язучыны мин начар педагогтан, телгә үзе дә формаль караган, битараф караган педагогтан белем алган язучы дип саныйм.*

*Туган телебезгә карата мәхәббәт тәрбияли алган укытучы бәхетле укытучы ул. Кеше рухын тәрбия укытучы ул. Рәмзия апаны мин әнә нәкъ шундый укытучы дип саныйм һәм шуңа күрә дә без, аның шәкертләре, аңа карата күңелебездә рәхмәт хисе саклап йөрибез. Аны хөрмәтләп баш иябез".*

Әйе, бөтен гомерен белем бирүгә, фәнгә багышлаган Рәмзия апа күңелендәге мәхәббәтнең иң олысы – Туган теленә багышланган. Сөекле тормыш иптәше Сәләй ага белән дә алар сәгатьләр буе бары тик бер генә нәрсә – әнә шул тел, аның грамматикасы, стилистик кагыйдәләре турында бәхәсләшкәннәр. Мөгаллимә туган телнең асыл сыйфатларын, кагыйдәләрен, мөмкинлекләрен укучылары күңеленә дә сеңдереп кала алган. Ул алып барган методика, матур язуга өйрәтү дәресләре турында бүген дә күпме хатирәләр яши.

Рәмзия апа бик күпләрне үзенең зыялы, тәрбияле булуы белән дә сокландырган, беркайчан да, беркемгә дә тавыш күтәргәнен хәтерләмиләр. Бары тик елмаеп, үз киңәшен биргән, туры юл күрсәткән. Шулай итеп ул укучылары өчен якын дус, сердәш тә була белгән һәм үзенә карата хөрмәт уяткан. Ә инде иҗади булуы, чисталыгы, пөхтәлеге, зәвыклы итеп киенә белүе белән әдәби әсәрләргә кадәр кергән. Г.Әдһәмнең: "Меңнәрнең берсе" бәянын гына алыйк:

*"Рәбига белән Салихтан да матуррак пар дөньяда булды микән?! Икесе дә яшь, чибәр, югары белемле! Сугыш алдыннан гына институт бетереп*

*укытырга кайтканнар иде. Училище яшьләренең гадәти тормышы үзгәрде дә куйды ул чакта. Кызлар, Рәбигага охшарга тырышып, аныңча итеп чәч үрергә, билләренә тар гына күн каеш буып йөрергә күнекте, ә малайлыктан чыгып җитмәгән үсмерләр, тарак күрмәгән тыңлаусыз чәчләрен Салих абыйларыныкы кебек артка чөеп җибәрергә гадәтләнделәр.*

*Ярты төнгә кадәр гөр килде училище. Рәбига оештырган драма түгәрәге «Беренче театр» белән башланды да ай саен бер спектакльне табадан төшереп кенә торды. Хан заманыннан калган киемнәр сандык төпләреннән актарылды, мунчала, сүс, ат кылларыннан сакал-мыек, чәч-париклар ясалды, грим өчен әллә никадәр буяу, майлар табылды. Әй күңелле чаклар!”*

Хатын-кыз, ана буларак Рәмзия Гыйлаҗ кызының иң көчле сыйфатлары – батыр, куркусыз булуы һәм тугрылык. Бернинди куркыту-өркетүләрдән дә, эшсез калудан да куркып тормыйча, ике сабыен ияртеп, ике тапкыр Печорага ире янына баруы, гаиләсен гомерлеккә саклап калу өчен, “кәгазьдә” генә аерылышуы, моңа тагын ирен яңадан мәгариф өлкәсенә кире кайтару, исемен аклау өчен башкарган эшләрен дә кушсаң, Рәмзия апаның көчле рухлы булуын сүзләр белән генә аңлатып булмас иде.

Димәк, Сәләй аганың Рәмзия апа белән беренче очрашу хатирәләре турындагы сүзләре хак булып чыга: “*Рәмзия бар яктан килгән, бик чибәр иде. Бишлегә генә укыды. Чыгышы белән аксөяк затлардан булып, нәсел җебе Рәмиевләргә тоташуына да, ниндидер туганнарының гарәп илләренең берсендә илчелектә эшләвенә дә карамастан, охшаш ягыбыз бар: икебез дә ятим. “бу кыз мине беркайчан да ташламас, башка андыйны таба алмам”,* - *дип уйладым. Инанганым дөрес булып чыкты...”*.

Ә үзенә иң катлаулы чорларда да терәк булуы турында Сәләй ага болай ди: Элекке язмаларда “Декабрист хатыннары” ирләрен эзләп, Байкал аръягына да барганнар, дип сокланып язалар иде. “Әмма минем Рәмзиям декабрист хатыны шикелле генә булмады. Мин бәхетле: мин шундый хатын белән гомер кичердем. ”

Әйе, Рәмзия Вәлитовага язмыш сынавын да, бәхетен дә өеп бирә: ятимлек, хаксызга рәнҗетүләр бәрабәренә килгән дан-шөһрәтләр, кадерле әни һәм сөекле хатын-кыз һәм үзе үлгәннән соң да укучылары күңелен җылытып торган хәтер-хатирәләр.

Менә шулай итеп, укучыларының йөрәгендә урын алырлык әдәби әсәрләргә керерлек укытучы остаз булу – үзе зур бәхет бит!

*Әлфия Төхфәтуллина*







